**КАРАР**
**Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Жуково авыл җирлегенең Жуково торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

**25 ноябрь 2019 ел** **№ 1**

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе нигезендә, 2019 елның 25 ноябрендә «Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районыны Жуково авыл җирлегенең Жуково торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, көндезге бүлектә укучы студентлар, Россия Федерациясе Кораллы Көчләре сафларына хезмәткә чакырылган гражданнардан тыш, 2020 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм аннан алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен, түбәндәге эшләрне башкару буенча юнәлдерүгә сез риза буласызмы:

- Жуково авылында урамнарны яктырту лампалары, яктырткычлар, махсус җиһазлар сатып алу, урнаштыру;
- Жуково авылыннан 3 км ераклыкта урнашкан зиратны койма белән әйләндереп алу өчен материал сатып алу;
- Жуково авылында су белән тәэмин итү челтәрләрен төзекләндерү?».

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булучы җыенда катнашучылар исемлегенә 166 кеше кертелде, гражданнар җыенында тавыш бирүдә катнашучылар саны – 85 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«РИЗА» позициясе өчен халык җыенында катнашучы 80 кеше тавыш бирде;

«КАРШЫ» позициясе өчен халык җыенында катнашучы 5 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының Жуково авыл җирлегенең Жуково торак пунктында гражданнар җыенын узган дип танырга, гражданнар җыенының нәтиҗәләре - дөрес дип танырга.

2. Әлеге мәсьәлә буенча: «Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районыны Жуково авыл җирлегенең Жуково торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, көндезге бүлектә укучы студентлар, Россия Федерациясе Кораллы Көчләре сафларына хезмәткә чакырылган гражданнардан тыш, 2020 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм аннан алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен, түбәндәге эшләрне башкару буенча юнәлдерүгә сез риза буласызмы:

- Жуково авылында урамнарны яктырту лампалары, яктырткычлар, махсус җиһазлар сатып алу, урнаштыру;
- Жуково авылыннан 3 км ераклыкта урнашкан зиратны койма белән әйләндереп алу өчен материал сатып алу;
- Жуково авылында су белән тәэмин итү челтәрләрен төзекләндерү?».

«ЗА» «ПРОТИВ»

карар кабул ителгән дип таныырга.

3. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен мәгълүмати стендларда урнаштыру юлы белән игълан итәргә, Тәтеш муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълъмат рәсми порталында урнаштырырга (PRAVO.TATARSTAN.RU).

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрергә.

**Халык җыенында**
**рәислек итүче** **Н.П. Сапожников**

**Татарстан Республикасы**
**Тәтеш муниципаль районы**
**Жуково авыл җирлеге башлыгы** **Н.П. Сапожников**